КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 9 апрель г.Казань № 218

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 сентябрь, 759 нчы; 2013 ел, 20 апрель, 272 нче; 2013 ел, 3 июль, 468 нче; 2013 ел, 18 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2016 ел, 16 сентябрь, 647 нче; 2017 ел, 2 август, 539 нчы; 2018 ел, 11 гыйнвар, 2 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктка «, коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәт күрсәтүләрне) куллану нормативлары» сүзләреннән соң «күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту кагыйдәләре һәм торак бүлмәне карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләре, күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда бүлмәләрне милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләрне күрсәтү, туктатып тору һәм чикләү кагыйдәләре таләпләре» сүзләрен өстәргә, «социаль файдалану (алга таба – мәҗбүри таләпләр),» сүзләреннән соң «җирле үзидарә органнары, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан торак-коммуналь хуҗалык дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә таләпләрне бозу,» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы

Премьер-министры А.В.Песошин